**СОВЕТ АЗЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д. 22,
с. Азеево, 423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢАЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКЪЯР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы,22 йорт
Акъяр авылы, 423190

тел.: (8-84348) 3-71-31, факс: (8-84348)3-7-61, Azeev.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Акъяр авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2025 елның 30 мае № 56-168

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Акъяр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Акъяр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 19, 86-88 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Акъяр авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советының 10.03.2015 № 52-114 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына (карарлар редакциясендә: 3-7 от 11.10.2015; № 11-21 от 19.02.2016; № 19-39 от 25.11.2016; № 24-53 от 17.04.2017; № 37-73 от 24.11.2017; № 46-87 от 17.05.2018; № 51-103 от 14.12.2018; № 57-121 от 10.07.2019; № 67-147 от 15.06.2020; № 13-34 от 31.05.2021; № 18-59 от 28.12.2021; № 24-81 от 7.07.2022; № 33-107 от 22.03.2023; № 44-137 от 8.04.2024; № 49-151 от 27.11.2024;) (алга таба – Устав) киләсе үзгәрешләр кертергә:

1.1. Уставның 1 статьясындагы 2 пунктында «Татарстан Республикасы» сүзләреннән соң «, кыскартылган исеме «Акъяр АҖ» сүзләрен өстәргә.

1.2. Уставның 30 статьясының 7.6 өлеше үз көчен югалткан дип танырга;

1.3. Уставның 34 статьясындагы 1 өлешенең 25 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1.4. Уставның 79 статьясындагы 6 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6. Чираттагы финанс елына һәм план чорына җирлек бюджеты проекты Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм җирлек Советы карары нигезендә җирлек башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә һәм вакытларда төзелә.».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда: https://pravo.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советының Законлылык, җирдән файдалану һәм территорияләрне төзекләндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Акъяр
авыл җирлеге башлыгы Д.С.Гайнуллин